КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 15 гыйнвар г.Казань № б-33

Татарстан Республикасы Президентының «Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көненә багышланган «Изге Болгар җыены» тантаналы чарасын әзерләүне һәм үткәрүне оештыру турында» 2017 елның 21 августындагы 718 номерлы Указының 2 пунктын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көненә багышланган «Изге Болгар җыены» тантаналы чарасын әзерләү һәм үткәрү буенча республика планын расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 апрель, б-912 нче боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 15 гыйнвар, б-33 нче
боерыгы белән расланды

2024 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көненә багышланган
«Изге Болгар җыены» тантаналы чарасын әзерләү һәм үткәрү буенча
республика планы

| Т/с | Чараның исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Россия Федерациясе субъектыннан, якын һәм ерак чит илләрдән татарларны чакыруны оештыру | 2024 елның 30 апреле | Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча) |
| 2. | Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көненә багышланган «Изге Болгар җыены» тантаналы чарасының мактаулы кунаклары исемлеген әзерләү | 2024 елның 30 апреле | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча), Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен торгызу республика фонды» (килешү буенча), Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте (килешү буенча) |
| 3. | Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары хезмәткәрләрен җәлеп итеп, тантаналы чара үткәрелә торган объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклану торышын тикшерүләр буенча график планын эшләү | 2024 елның 30 апреле | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 4. | Тантаналы чараны үткәрү урыны тирәсендә сәүдә нокталарының, күчмә сәүдә һәм җәмәгать туклануы пунктларының килештерелгән схемасын әзерләү һәм аларның урнашу урыннарын билгеләү | 2024 елның 30 апреле | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 5. | Гражданнарны эвакуацияләү ихтималын исәпкә алып, автотранспортны санкцияләнгән парковкалау урынын билгеләү. Чараның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен техник чараларның кирәкле күләмен исәпләү, юл хәрәкәтен һәм парковкаларны оештыру схемасын эшләү | 2024 елның 30 апреле | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 6. | Тантаналы чара үткәрү урыннарында, юл йөрү маршрутларында әлеге чараларның кунакларына һәм аларда катнашучыларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру өчен ашыгыч медицина ярдәме бригадасы урнашу урыннарын билгеләү, ашыгыч медицина ярдәме бригадасы урнашу урыннарының килештерелгән схемасын әзерләү | 2024 елның 30 апреле | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 7. | Тантаналы чара программасын әзерләү һәм үткәрүне оештыру | 2024 елның 30 апреле | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Бөтендөнья татар конгрессы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча), Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте (килешү буенча) |
| 8. | «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе территориясен тиешле санитария-экология хәленә китерү (музей-тыюлык территориясен санитар эшкәр-тү, дини йолалар үткәрү урыннарына агымдагы ремонт ясау һәм аларны төзекләндерү, тантаналы чараларда катнашучыларны гигиена чаралары белән тәэмин итү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм башкалар) | 2024 елның 10 мае | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 9. | Туклануны оештыру буенча хезмәтләр күрсә-түче юридик затлар һәм индивидуаль эшмә-кәрләр тарафыннан Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты белән сатыла торган ашамлыклар һәм азык-төлек продуктларының ассортимент исемлек-ләрен һәм менюларны килештерүне тәэмин итү | 2024 елның 10 мае | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 10. | Тантаналы чара үткәрү территориясендә, шулай ук анда катнашучылар яшәү һәм туклану урыннарында профилактик чаралар үткәрүне оештыру | 2024 елның 14 мае | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 11. | Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары төзеклеген тәэмин итү, шул исәптән юл билгеләре, транспорт хәрәкәте маршрутлары буенча куркынычсызлык киртәләре булуны тәэмин итү | 2024 елның 14 мае | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 12. | Чараны оештыру урыннарында дезинсекция һәм дератизация эшләре башкаруны тәэмин итү | 2024 елның 18 мае | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 13. | Тантаналы чара үткәрү вакытында Россия Федерациясе законнары нигезендә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыру | 2024 елның 18 – 19 мае | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 14. | Тантаналы чара вакытында шартнамә нигезендә ашыгыч медицина ярдәме бригадаларының кизү торуын тәэмин итү | 2024 елның 18 – 19 мае | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 15. | Чара оештыручыларга тантаналы чара вакытында Россия Федерациясе законнары нигезендә гражданнар иминлеген һәм иҗтимагый тәртипне тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | 2024 елның 18 – 19 мае | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 16. | Чара оештыручыларга тантаналы чара үткәрү урыннарында Россия Федерациясе законнары нигезендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | 2024 елның 18 – 19 мае | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 17. | Объектларны техник саклау чаралары һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү системалары (металл детекторлары, барьер киртәләр, вакытлыча тикшереп үткәрү пунктлары) белән тәэмин итү. Гражданнарны һәм алар янындагы әйберләрне тикшерүне гамәлгә ашыру өчен квалификацияле хосусый саклау оешмалары хезмәткәрләрен җәлеп итү | 2024 елның 18 – 19 мае | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 18. | Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре ярминкәсен оештыру һәм үткәрү | 2024 елның 18 – 19 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау буенча ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 19. | Тантаналы чара үткәрү вакытында «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе территориясендә туклану пунктларын оештыру | 2024 елның 18 – 19 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге (килешү буенча), «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 20. | Туклануны оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүче юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан санитария законнары таләпләре, техник җайга салу өлкәсендәге, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендәге таләпләр, «Хәләл» стандарты таләпләре һәм яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) профилактикалау буенча тәкъдимнәр үтәлешен тәэмин итү | 2024 елның 18 – 19 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге (килешү буенча), «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (килешү буенча) |
| 21. | «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең борынгы | 2024 елның 19 мае | Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | мәчете территориясендә «Ислам» темасына лекцияләр үткәрү, намаз дәресләрен, яулык бәйләү (хатын-кызлар өчен), татар чалмасын бизәкләү (ир-атлар өчен) буенча масстер-класслар оештыру һәм үткәрү | | |
| 22. | Барлык яшь категорияләре өчен урта гасыр каләм караларын җитештерү технологияләре, гарәп каллиграфиясе өйрәнелә торган «Язу тарихы» интерактив мәйданчыгы | 2024 елның 19 мае | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 23. | Чарада катнаша торган объектларда кизү тору өчен Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе һәм Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең җәлеп ителә торган шәхси составын ризык белән тәэмин итү | 2024 елның 19 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча (килешү буенча), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 24. | Тантаналы чара үткәрү объектларында, катнашучыларның яшәү һәм туклану урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешен тәэмин итү | 2024 елның 19 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | учреждениесе, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча (килешү буенча), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы |
| 25. | Тантаналы чарада «Милли үзенчәлек һәм дин» XIV Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы делегатларының катнашуын оештыру | 2024 елның 19 мае | Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 26. | Федераль һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларында тантаналы чараны мәгълүмати яктыртуны тәэмин итү | 2024 елның мае | Республика «Татмедиа» матбугат һәм масса-күләм коммуникацияләр агентлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Рәисе-нең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча), Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (килешү буенча) |
| 27. | Тантаналы чараны әзерләүгә һәм уздыруга багышланган матбугат конференциясен үткәрү | 2024 елның мае | «Татмедиа» Республика матбугат һәм масса-күләм коммуникацияләр буенча агентлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма коми-теты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |